ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__82_ от «_29_»____01____2018 г.

“2018 елга Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген арттыру”
максатчан программасы турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру " федераль максатчан программасы Концепциясен раслау турында” 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы күрсәтмәсен, "2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру" Федераль максатчан программасы турында" 2013 елның 3 октябрендәге 864 номерлы РФ Хөкүмәте карарын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 ел, 6 декабрь, ПУ-1115 нче Указын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору дәүләт программасын раслау турында” 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче санлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар турында» 2016 ел, 27 декабрь, 1011 санлы карарын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.“2018 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру” максатчан программасын расларга (алга таба-программа) (1 № лы Кушымта);

2.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына район бюджетын һәм капиталь кертемнәр программасын формалаштырганда Программа чараларын тормышка ашыру өчен акча каарга.

3. Тәкъдим итәргә:

- Мамадыш шәһәре һәм авыл җирлекләре башкарма комитетларына, «Мамадыш ЖКУ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә, «Татавтодор» АҖ Мамадыш филиалына торак пунктларда урам-юл челтәрен һәм юл хәрәкәтен техник җайга салу чараларын сыйфатлы карап тоту буенча чаралар үтәлешен тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты МКУ “Мәгариф бүлегенә” гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне

гамәлгә ашыручы автотранспорт йөртүчеләрнең һөнәри осталыгы дәрәҗәсенә, мәктәп автобусларының техник халәтенә карата булган таләпләрне арттырырга;

- территориаль инфраструктур үсеш бүлекләренә, Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты МКУ “Мәгариф бүлегенә”, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының “Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” муниципаль учреждениесенә, Мамадыш үзәк район хастаханәсенә Программаның үтәлеше турында квартал саен анализ ясарга һәм мәгълүматны һәр айның 5 нче көненә кадәр муниципаль районы башкарма комитетына хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерегә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны үз контролемә алам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов